Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Кармалка торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2022 елның 20 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлегенең Кармалка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлеге Кармалка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлеге Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 85 яшьтән өлкәнрәкләр һәм балалары махсус хәрби операциядә катнашучы һәм һәлак булганнарның ата-аналардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

- Нагорная һәм Заречная урамнары арасындагы юлдагы чокырларны ямау
- гыйбадәтханә каршындагы машина кую урыны.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү оештыру

- су өзеклекләрен бетерү.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Кармалка авыл җирлеге составына керүче Мордва Кармалкасы торак пунктында 2016 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану референдумы нигезендә җыелган калган гражданнар үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә белән килешәсезме:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

- Нагорная һәм Заречная урамнары арасындагы юлдагы чокырларны ямау
- гыйбадәтханә каршындагы машина кую урыны.

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә

җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү оештыру

- су өзеклекләрен бетерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия ур., 38 а йорт, 2 корылма (административ бина), Нагорный ур., 33 йорт (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы О.В.Кириллова